# КАМА БУЕ - ТУГАН ЯК

*ФӘТХЕРАХМАН ӘХМӘДИЕВ музыкасы*
*РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ сүзләре*

Акчарлаклар оча уйнап
Агым су өсләрендә.
Син җылы бирдең, туган як,
Иң якты хисләремә.

*Кушымта:*
Кама буе--туган як,
Гөлләр үсә торган як;
Гүзәллеге күңелләрдән
Җырга күчә торган як.

Шаулый зәңгәр урманнарың,
Көч алам суларыңнан.
Күпме барсам да армам күк
Бормалы юлларыңнан.

*Кушымта.*